КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 25 апрель г.Казань № 266

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 27 апрель, 211 нче, 2006 ел, 15 июнь, 303 нче, 2006 ел, 17 июль, 366 нчы, 2008 ел, 25 июль, 536 нчы, 2009 ел, 30 март, 192 нче, 2009 ел, 25 май, 333 нче, 2009 ел, 24 декабрь, 879 нчы, 2011 ел, 23 май, 404 нче, 2011 ел, 21 декабрь, 1027 нче, 2012 ел, 06 февраль, 86 нчы, 2012 ел, 17 июль, 605 нче, 2012 ел, 20 декабрь, 1110 нчы, 2013 ел, 31 май, 367 нче, 2017 ел, 14 гыйнвар, 7 нче, 2017 ел, 13 сентябрь, 668 нче, 2019 ел, 17 декабрь, 1159 нчы, 2022 ел, 27 декабрь, 1427 нче, 2023 ел, 25 февраль, 184 нче, 2023 ел, 25 март, 350 нче, 2024 ел, 6 май, 299 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

татар текстында 1.7 пунктта «аренда шартнамәсе» сүзләренә кадәр «җир кишәрлегенең» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 1.12 пункт өстәргә:

«1.12. Аарення түләве ел саен, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзелгәннән соң бер елдан да иртәрәк булмаган срокта, әлеге Нигезләмәнең 1.6 һәм 1.7 пунктларында каралган очраклардан тыш, арендага бирүче тарафыннан

чираттагы финанс елы башына җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзелгән елдан башлап ел саен кулланыла торган  чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында федераль законда билгеләнгән инфляция дәрәҗәсе күләменә берьяклы тәртиптә үзгәртелә. Әлеге Нигезләмәнең 1.10 пунктының беренче абзацында каралган очракта, инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, аренда түләвен индексацияләү үткәрелми. Арендага бирелә торган җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәрү елында инфляция дәрәҗәсе күләмендә аренда түләвен үзгәртү гамәлгә ашырылмый.

Инфляция дәрәҗәсе күләмендә аренда түләвен үзгәртү мөмкинлеге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсендә карала.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Җир кишәрлегеннән файдаланган өчен еллык аренда түләве күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$А = Кс \times Рс \times Кф,,$$

монда:

А – җир кишәрлегеннән файдаланган өчен еллык аренда түләве күләме;

Кс – җир кишәрлегенең кадастр бәясе;

Рс – җир салымы ставкасы күләме;

Кф – әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган төзәтү коэффициенты.»;

әлеге Нигезләмәгә кушымтада «Сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналар идарәче компанияләре идарәсендәге индустриаль парклар инфраструктурасы объектларына (төзелеш чорын да кертеп)» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм аңа якын муниципаль берәмлекләр территориясендә инвестицияләрнең күләме кимендә 100 млрд. сум (төзелеш чорын да кертеп) булган масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыра торган, устав капиталында Татарстан Республикасының катнашу өлеше 50 проценттан артыграк булган индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләре карамагындагы, Россия Федерациясе Җир кодексының 396 статьясындагы 2 пунктының 3 пункты нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан индустриаль паркларның инфраструктура объектлары | 20». |

2. Әлеге карар үз көченә кергәннән соң төзелгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата әлеге карар кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин